*Хуснуллина Айнур Мирзязановна*

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение “Средняя общеобразовательная школа №45 с углубленным изучением отдельных предметов”*

*город Набережные Челны*

# КОНСПЕКТ УРОКА ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА ПО ТЕМЕ “ТАТАРСТАН – ТУГАН ҖИРЕМ” ВО 2 КЛАССЕ ДЛЯ РУССКОЯЗЫЧНЫХ УЧАЩИХСЯ

Тема: Татарстан - туган җирем.

Максат: 1. Татарстанның табигате турында сүзтезмәләр, җөмләләр төзергә өйрәнү.

2. Яңа сүзләр белән таныштыру: усал, хәйләкәр, куе, озын, поши.

3.Диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.

4. Татарстан Республикасы турында белемнәрен киңәйтү.

Җиhазлау: презентация, сүзләр язылган карточкалар.

Дәреснең барышы.

1.Оештыру өлеше.

— Исәнләшү.

— Сыйныфта кемнең булмавын әйтү.

— Һава торышын сөйләү.

2.Актуализация.

Без нинди республикада яшибез?

Сез шәһәрдә яшисезме, авылда яшисезме? Сез Казанда яшисезме? Сез нинди шәһәрдә яшисез? Татарстан нинди республика? Татарстанда нәрсәләр бар? Татарстанда нинди шәһәрләр бар? Без бүген нәрсә турында сөйләшербез?

Әйе, без бүген туган ягыбыз, Татарстаныбыз турында сүзләр өйрәнербез, җөмләләр төзербез, сөйләргә өйрәнербез.

3. Сүзлек өстендә эш. Сүзләрне дөрес әйтү күнегүләре һәм сүзлекләр белән эш, тәрҗемә итү, сүзлек дәфтәрләренә язу.

a) туган як [т у гъ а н й а къ] күл [к ү л]
   туган җир [т у гъ а н җ и р] кыр[къ ы р]
   табигать [т а б и гъ ә т] озын [о з о н ]
   киң [к и ң] хәйләкәр [х ә й л ә к ә р]
   куе [къ у й ы] усал [у с а л]

b) Скажите по-русски: озын елгалар, киң кырлар, куе урманнар, хәйләкәр төлкеләр, усал бүреләр, матур күлләр, бай табигать, киң елга.

c) Скажите по-татарски: злые волки, хитрые лисы, длинные реки, широкие поля, густые леса, красивые озера, богатая природа, широкая река.

d) Татарстан, шәһәр, республика сүзләрен минем, безнең сүзләре белән әйтегез (минем Татарстаным, безнең Татарстаныбыз... )

4. Дәреслек белән эш.

104 бит 1, 2, 3 телдән.

5. Карточкаларны алыгыз, күплек сан кушымчаларын языгыз (Урман_____, кыр____, күл____, поши____, аю____, бүре_____, төлкe_____, куян_____, елга_____, шәһәр_____, тиен_____.) Эшне тикшерү.

6. Экранда презентация белән эшләү.

- ✓ 1 нче бирем: бирелгән сүзләрне үз өйләренә урнаштырыгыз.
- ✓ 2 нче бирем. Сүзләрнең парын табыгыз.

7. Скажи, что ты

— живешь в Татарстане;

— живешь в городе;

— живешь в Набережных Челнах.

Спроси у друга:

— где он живет;

— в каком городе он живет;

— любит ли он Набережные Челны;

— около какой реки расположен город Набережные Челны?

8. Дәреснең йомгагы, өй эше бирү. Татарстан табигате турында презентация күрсәтү.